**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Азнакай шәһәре Советы (өченче чакырылыш)**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 186-44 «24 » август 2020 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советының 2018 елның 19 апрелендәге 97-25 номерлы «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында " карары белән расланган, бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру һәм бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 5 августындагы 655 номерлы «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында" карары нигезендә, бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары җитәкчеләренә, белгечләренә һәм хезмәткәрләренә социаль гарантияләрне тәэмин итү максатыннан

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советы карар **итте**:

1. 2020 елның 01 октябреннән, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советының 2018 елның 19 апрелендәге 97-25 номерлы «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында " карары белән билгеләнгән, бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладлары күләмен арттырыга.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советының 2018

елның 19 апрелендәге 97-25 номерлы «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында " карары белән расланган, бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1.4 пунктта. «11 163,00» санын «11498,00»санына алмаштырырга.

3. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М. З. Шәйдуллин